**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2011 ел, 14 февраль

№ 97

г. Казань

Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче пенсионерларны савыктыру, аларга ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавыннан файдалану мөмкинлеген күбрәк бирү өлешендә социаль ярдәм күрсәтү чараларын камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибен (карарга теркәлә) расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт социаль ярдәме турында» 2004 ел, 17 декабрь, 541 нче карары белән расланган Дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 нче пункттагы «шифаханә-курорт дәвалавына юлламалар» дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

1.6 нчы пункттагы икенче абзацны төшереп калдырырга;

2.1 нче пункттагы дүртенче абзацны төшереп калдырырга.

3. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итүгә бәйле чыгымнарны финанслауны чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында бу максатларга күздә тотылган акча чикләрендә башкарырга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2011\97.doc

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 14 февраль, 97 нче карары белән расланды

**Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибе**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибе (алга таба – Тәртип) Татарстан Республикасы пенсионерларына шифаханә-курорт дәвалавына Татарстан Республикасы акчасы исәбеннән сатып алынган юлламаларны бирү шартларын билгели.

1.2. Ташламалы шартларда юлламалар белән Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәүче, гаиләсенең җан башына исәпләнгән уртача кереме Татарстан Республикасы буенча халыкның җан башына яшәү минимумы күләменең 400 процентыннан артмаган пенсионерлар (Россия Федерациясенең норматив хокук актлары нигезендә халыкның шифаханә-курорт дәвалавына хокуклы категорияләренә кергән гражданнардан тыш), шифаханә-курорт дәвалавына мохтаҗлык турында тиешле медицина бәяләмәсе булган шартларда (алга таба – гражданнар) тәэмин ителә.

1.3. Гаиләнең җан башына уртача кереме күләмен хисаплап чыгару тәртибе гражданнарга дәүләт социаль ярдәмен билгеләгәндә кулланыла торган тәртипкә охшаш.

1.4. Шифаханә-курорт юлламасы өчен пенсионерның үз акчасын түләү күләме бу Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымта нигезендә хисаплап чыгарыла, ул пенсионер гаиләсенең җан башына исәпләнгән уртача кеременә бәйле була.

1.5. Шифаханә-курорт оешмаларында шифаханә-курорт дәвалануы вакыты озынлыгы 18 көн тәшкил итә.

## 2. Шифаханә-курорт дәвалавына юллама сорап мөрәҗәгать итү тәртибе

2.1. Бу Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымтада күрсәтелгән форма буенча шифаханә-курорт дәвалавын алу турында гариза граждан тарафыннан язма рәвештә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының гариза бирүче даими яшәгән урын буенча территориаль социаль яклау органына (алга таба – территориаль социаль яклау органы) кертелә.

Гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

тиешле сәламәтлек саклау учреждениесе биргән медицина бәяләмәсе;

пенсия таныклыгы күчермәсе;

торак-эксплуатация идарәсеннән гаилә составы турында белешмә;

гариза тапшыра торган ай алдыннан килгән өч ай өчен гаиләнең һәр әгъзасы керемнәре турында белешмә.

Гариза тапшырганда гариза бирүченең шәхесен раслый торган документ күрсәтелә.

2.2. Территориаль социаль яклау органы:

барлык кирәкле документлар белән бергә гариза керткән көннән алып 10 көн эчендә гражданны юллама алу өчен исәпкә кую яки куюдан баш тарту турында карар кабул итә һәм тиешле карарны гражданга җиткерә;

гражданның шәхси эшен аңа кертелгән документларны һәм юллама алу өчен аны исәпкә кую турындагы карарны кертеп формалаштыра;

гариза тапшыру көненә карап, шифаханә-курорт дәвалавына мохтаҗ гражданнар исемлекләрен төзи.

## 3. Шифаханә-курорт дәвалавына юлламалар бүлү һәм бирү тәртибе

3.1. Территориаль социаль яклау органы:

чират нигезендә гражданнарга шифаханә дәвалавы юнәлеше буенча юлламалар керү турында хәбәр итә;

юлламалар кергән көннән алып 10 көн эчендә бу Тәртипнең 2.1 нче пунктында күрсәтелгән, граждан тарафыннан яңартылган документлар нигезендә гражданга юллама бирү (яки аны бирүдән баш тарту) турында карар кабул итә.

3.2. Юллама гражданга аның кыйммәтенә бу Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымта нигезендә исәпләнгән күләмнәрдә түләгәннән соң бирелә. Түләү, шифаханә-курорт дәвалавына кергән акчаны алга таба максатчан сарыф итүне күздә тотып, «Ак Барс» акционерлар коммерция банкы» ачык акционерлар җәмгыятенең район филиалларында Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы исәбенә кертелә.

3.3. Алучыга юллама аның гамәли вакыты җиткәнгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча бирелә.

3.4. Гражданга юллама елга бер тапкырдан артык бирелми.

## 4. Юлламаларны исәпкә алу һәм саклау

4.1. Юлламалар катгый хисаплылык документлары булып санала һәм акча белән бер үк дәрәҗәдә сакланырга һәм исәпкә алынырга тиеш.

4.2. Юлламаларны исәпкә алу территориаль социаль яклау органнарында керемнәр документлары (Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгыннан йөкнамәләр) нигезендә шифаханә-курорт дәвалавына юлламаларны исәпкә алу һәм бүлү кенәгәсендә аларны саклауга кабул иткән зат тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.3. Гражданның шифаханә-курорт учреждениесендә булганлыгын раслый торган документ булып шифаханә-курорт юлламасының граждан тарафыннан территориаль социаль яклау органына кире кайтарылучы ертып алына торган талоны санала,

4.4. Шифаханә-курорт юлламаларыннан файдалану турындагы хисаплар территориаль социаль яклау органы тарафыннан Татарстан Республикасының

Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына елга 2 тапкыр кертелә:

беренче яртыеллык өчен – 10 июльгә кадәр,

узган ел өчен – хисап елыннан соң килүче елның 10 гыйнварына кадәр.

4.5. Бу Тәртиптә бәян ителгән кагыйдәләрнең үтәлеше өчен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль социаль яклау органнары башлыклары җавап бирә.

4.6. Бу Тәртипне бозган өчен гаепле затлар гамәлдәге законнар белән билгеләнгән тәртиптә җавап бирә.

F:\KARAR\2011\97-1.doc

Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенә 1 нче кушымта

Шифаханә-курорт юлламасы өчен пенсионер үзе түли торган акча күләме

| Төркем | Пенсионер гаиләсенең җан башына исәпләнгән уртача кереме күләме халыкның җан башына яшәү минимумы күләменә карата процентларда | Шифаханә-курорт юлламасы өчен пенсионер үзе түли торган акча күләме, юллама кыйммәтеннән процент |
|---|---|---|
| I | 200 гә кадәр (200 не кертеп) | 5 |
| II | 200 дән артык 250 гә кадәр (250 не кертеп) | 10 |
| III | 250 дән артык 300 гә кадәр (300 не кертеп) | 15 |
| IV | 300 дән артык 350 гә кадәр (350 не кертеп) | 20 |
| V | 350 дән артык 400 гә кадәр (400 не кертеп) | 25 |

F:\KARAR\2011\97-2.doc

Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курорт дәвалавы белән тәэмин итү тәртибенә 2 нче кушымта

Форма

Татарстан Республикасы ___________________ муниципаль районы (шәһәр округы) территориаль социаль яклау органына

________________________________________

_________________ адресы буенча яши торган

_________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
_________________________________________
телефон __________________________________
паспорт сериясе_________ №_____________

ГАРИЗА

Миңа медицина бәяләмәсе нигезендә 20 ________ елның ________________
(ай)
_________________________________ шифаханәсенә юллама бирүегезне үтенәм.
(исеме)
Юлламаны соңгы тапкыр 20____ елның ______________________ алган идем.
(ае)

Гаризага түбәндәгеләрне терким:
1.Медицина белешмәсен – ___ данә.
2. Гаилә составым турында белешмә – ___ данә.
3. Гаилә әгъзаларым керемнәре турында белешмә – ___ данә.
4. Пенсия таныклыгым күчермәсен – ___ данә.

Башкасы _______________________________________________ (күрсәтергә).

Дата _______________ Гариза бирүченең имзасы ______________________